КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2026 ел, 7 апрель г.Казань № 351

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Аерым юнәлешләр буенча агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме чаралары турында» 2021 ел, 30 июнь, 514 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Аерым юнәлешләр буенча агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме чаралары турында» 2021 ел, 30 июнь, 514 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 5 август, 680 нче; 2021 ел, 31 август, 788 нче; 2021 ел, 7 сентябрь, 835 нче; 2021 ел, 25 ноябрь, 1127 нче; 2021 ел, 22 декабрь, 1266 нчы; 2022 ел, 15 март, 240 нчы; 2022 ел, 22 июль, 707 нче; 2022 ел, 16 сентябрь, 1009 нчы; 2022 ел, 13 декабрь, 1319 нчы; 2022 ел, 21 декабрь, 1389 нчы; 2023 ел, 21 февраль, 168 нче; 2023 ел, 4 июль, 786 нчы; 2023 ел, 9 август, 961 нче; 2023 ел, 5 октябрь, 1239 нчы; 2024 ел, 4 март, 119 нчы; 2024 ел, 17 апрель, 258 нче; 2024 ел, 10 май, 317 нче; 2024 ел, 5 август, 622 нче; 2024 ел, 10 октябрь, 875 нче; 2025 ел, 4 апрель, 197 нче; 2025 ел, 16 июнь, 436 нчы; 2025 ел, 30 июль, 558 нче; 2025 ел, 24 декабрь, 1140 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбулада «2013 – 2023 елларга» сүзләрен төшереп калдырырга;

1 пунктта:

икенче абзацта «җитештерелгән орлыкларны» сүзләрен «булдырылган авыл хуҗалыгы культуралары сортлары һәм (яки) гибридлары орлыкларын» сүзләренә алмаштырырга;

унынчы абзац үз көчен югалткан дип танырга;

унҗиденче абзацта татар текстында «терлекчелеккә ярдәм күрсәтүгә» сүзләреннән соң «һәм авыл хуҗалыгы хайваннарының нәселле яшь терлеген сатып алуга» сүзләрен өстәргә;

егерме бишенче абзац үз көчен югалткан дип танырга;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Мөгезле эре терлек, кәҗә һәм сарыкның эшкәртелмәгән сөтен азык-төлек продукциясенә эшкәртүгә ярдәм күрсәтү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджеттан финанслаша торган субсидия бирү тәртибен.»;

әлеге карар белән расланган Федераль фәнни-техник программа кысаларында җитештерелгән элиталы орлыкчылыкка ярдәм күрсәтү һәм (яки) орлыклар сатып алу өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджеттан финанслаша торган субсидия бирү тәртибендә:

исемендә татар текстында «җитештерелгән» сүзен «булдырылган» сүзенә алмаштырырга, «орлыклар» сүзен «авыл хуҗалыгы культураларының сортлары һәм (яки) гибридлары орлыкларын» сүзләренә алмаштырырга;

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Әлеге Тәртип Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2017 – 2030 елларга авыл хуҗалыгын үстерү буенча федераль фәнни-техник программаны раслау турында» 2017 елның 25 августындагы 996 номерлы карары белән расланган Федераль фәнни-техник программа кысаларында булдырылган элиталы орлыкчылыкка ярдәм күрсәтү һәм (яки) авыл хуҗалыгы культураларының сортлары һәм (яки) гибридлары орлыкларын сатып алу өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджеттан финанслаша торган субсидия (алга таба шул ук эзлеклелектә – ФФТП, субсидия) бирү шартларын һәм тәртибен билгели.

Субсидия түбәндәгеләр өчен бирелә:

а) Файдаланырга рөхсәт ителгән авыл хуҗалыгы үсемлекләренең сортлары һәм гибридлары буенча дәүләт реестрына (алга таба – Дәүләт реестры) белешмәләре кертелгән авыл хуҗалыгы культураларының элиталы орлыкларын (агымдагы финанс елы уңышын чәчү өчен кулланылган бәрәңгенең һәм (яки) яшелчә культураларының оригиналь һәм элиталы орлыкларыннан (өстәлгән кыйммәткә салымны исәпкә алмыйча) тыш) сатып алу өчен агымдагы финанс елы һәм (яки) агымдагы финанс елына кадәрге ел чыгымнарының бер өлешен әлеге авыл хуҗалыгы культуралары турында белешмәләр түбәндәге шартларның берсенә туры килгәндә каплауга:

авыл хуҗалыгы үсемлекләренең сортлары һәм гибридлары турында белешмәләрне Дәүләт реестрына кертү һәм авыл хуҗалыгы үсемлекләренең билгеләрен һәм (яки) үзлекләрен сынау өчен заявкада күрсәтелгән Дәүләт реестры мәгълүматлары буенча заявка бирүчеләр – 2024 елның 31 декабренә карата Дәүләт реестры белешмәләрендә (2024 елның 31 декабреннән соң Дәүләт реестрына кертелгән сортлар һәм гибридлар өчен – мондый заявка бирү датасына карата) адресы итеп Россия Федерациясе территориясе күрсәтелгән дәүләт учреждениесе, яки оешма, шул исәптән фәнни яки мәгариф оешмасы, яки берничә дәүләт учреждениесе һәм шундый оешмалар;

авыл хуҗалыгы үсемлекләренең сортлары һәм гибридлары турында белешмәләрне Дәүләт реестрына кертү һәм авыл хуҗалыгы үсемлекләренең билгеләрен һәм (яки) үзлекләрен сынау өчен заявкада күрсәтелгән Дәүләт реестры мәгълүматлары

буенча заявка бирүчеләр – Дәүләт реестры белешмәләрендә адресы итеп Россия Федерациясе территориясе күрсәтелгән Россия физик заты (Россия индивидуаль эшмәкәрне кертеп) яки Россия Федерациясе законнары нигезендә Россия Федерациясе территориясендә теркәлгән, устав капиталында чит ил физик затларының һәм (яки) чит ил юридик затларының (теләсә нинди оештыру-хокук рәвешендәге) катнашу өлешләре булмаган Россия юридик заты яки Дәүләт реестры мәгълүматлары буенча авыл хуҗалыгы үсемлекләренең сорты яки гибриды авторлары буларак Дәүләт реестры белешмәләрендә адресы итеп Россия Федерациясе территориясендәге адрес күрсәтелгән Россия физик заты яки берничә шундый Россия физик затлары күрсәтелү һәм мондый авторлар турында белешмәләр Дәүләт реестрына кертелү шарты белән әлеге физик зат һәм юридик зат.

Белешмәләрнең күрсәтелгән шартларга туры килүен тикшерү Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла;

б) билгеләнгән агротехнология срокларын исәпкә алып, сатып алган яки аннан соңгы елда сатып алынган орлыкларны чәчү шарт белән, ФФТП кысаларында булдырылган мондый авыл хуҗалыгы үсемлекләре сортлары һәм (яки) гибридлары орлыкларын реализацияләүнең әлеге Тәртиптә билгеләнгән иң чик кыйммәтеннән артмый торган кыйммәтеннән чыгып, агымдагы финанс елындагы һәм (яки) агымдагы финанс елына кадәрге елдагы авыл хуҗалыгы үсемлекләре сортлары һәм (яки) гибридлары орлыкларын сатып алуга тотылган чыгымнарның бер өлешен каплауга.

Субсидия түбәндәге субсидия алучылар категорияләренә бирелә:

әлеге пунктның «а» пунктчасында күрсәтелгән юнәлеш буенча – авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләргә (шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнардан һәм авыл хуҗалыгы кредит кулланучылар кооперативларыннан тыш);

әлеге пунктның «б» пунктчасында күрсәтелгән юнәлеш буенча – авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләргә (шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнардан һәм авыл хуҗалыгы кредит кулланучылар кооперативларыннан тыш), авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерүне, беренчел һәм (яки) аннан соңгы (сәнәгый) эшкәртүне гамәлгә ашыручы оешмаларга һәм индивидуаль эшкуарларга, фәнни һәм мәгариф оешмаларына.

Салым түләүченең өстәлгән кыйммәткә салым исәпләүгә һәм түләүгә бәйле йөкләмәләрен үтәүдән азат итү хокукыннан файдаланучы субсидия алучылар өчен чыгымнарның бер өлешен каплау товарлар (эшләр, хезмәт күрсәтүләр) сатып алу чыгымнары суммасыннан (өстәлгән кыйммәткә салым суммасын кертеп) чыгып гамәлгә ашырыла.»;

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Әлеге Тәртиптә «фәнни һәм мәгариф оешмалары» төшенчәсе кулланыла, ул «Авыл хуҗалыгын үстерү турында» 2006 елның 29 декабрендәге 264-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясындагы 1 өлешендә күрсәтелгән исемлек нигезендә фәнни, фәнни-техник һәм (яки) белем бирү эшчәнлеге барышында авыл хуҗалыгы продукциясе җитештерүне, аны беренчел һәм аннан соңгы (сәнәгый) эшкәртүне гамәлгә ашыра торган фәнни оешмалар, һөнәри белем бирү оешмалары, югары белем бирү мәгариф оешмалары дигәнне аңлата.»;

4 пунктта «Министерлык» сүзен «Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы (алга таба – Министрлык)» сүзләренә алмаштырырга;

5 пунктта:

«Бюджет» бүлегендә» сүзләрен «(бердәм портал бүлегендә)» сүзләренә алмаштырырга;

татар текстында «мәгълүмат» сүзеннән соң «субсидия бирү өчен бюджет ассигнованиеләре Министрлыкка җиткерелгән көннән соң килә торган көннән алып 10 эш көне эчендә» сүзләрен өстәргә;

11 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11. Субсидия түбәндәге шартларда бирелә:

«Авыл хуҗалыгы иминияте өлкәсендә дәүләт ярдәме турында һәм «Авыл хуҗалыгын үстерү турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2011 елның 25 июлендәге 260-ФЗ номерлы Федераль законның 8 статьясындагы 1 өлешенең 1 пунктында каралган барлык яки берничә вакыйга һәм (яки) «Авыл хуҗалыгы иминияте өлкәсендә дәүләт ярдәме турында һәм «Авыл хуҗалыгын үстерү турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2011 елның 25 июлендәге 260-ФЗ номерлы Федераль законның 8 статьясындагы 1 өлешенең 4 пунктында каралган вакыйгалар килеп чыгу аркасында субсидия алучы тарафыннан чәчү мәйданнарына карата авыл хуҗалыгы культурасы уңышын югалту (уңышы юкка чыгу) рискларын иминләштерү;

заявка биргән елга кадәрге елда авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдә корыган үләнчел үсемлекләрне, камыл үләннәрен, камыл калдыкларын (дөге саламыннан тыш) яндыру өчен Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясендә янгынга каршы режим кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 16 сентябрендәге 1479 номерлы карарында билгеләнгән тыюны үтәмәгән өчен субсидия алучыларны Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының $20^4$ статьясы буенча административ җаваплылыкка тарту;

субсидия алучы тарафыннан Министрлык белән субсидия алучы арасында төзелгән субсидия бирү турындагы килешү (алга таба – килешү) нигезендә субсидия алынган елда субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү турында йөкләмәләр кабул ителү;

Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы ведомствосы буйсынуында булган, сайлап алуда катнашучы эшчәнлек гамәлгә ашырган мелиорация өлкәсендәге федераль дәүләт бюджет учреждениесенең әлеге учреждениегә сайлап алуда катнашучының су бирү (чыгару) хезмәтләре өчен үз вакытында түләнмәгән бурычы һәм (яки) әлеге учреждениенең суд тарафыннан эшкә алынган субсидия алучыдан су бирү (чыгару) хезмәтләре күрсәтү шартнамәсе буенча 50 мең сумнан арткан күләмдә бурыч акчасын түләтү турында дәгъва гаризасы булмау хакында белешмә кәгазе булу (әлеге белешмә кәгазе булмаса, Министрлык аны мөстәкыйль рәвештә, шул исәптән берничә субсидия алучыларга карата, соратып ала);

субсидия алучыда әлеге Тәртипнең 1 пунктындагы «а» һәм (яки) «б» пунктчаларында күрсәтелгән авыл хуҗалыгы культуралары орлыклары чәчелгән чәчү мәйданнары булу;

сайлап алуда катнашучыларның әлеге Тәртипнең 1 пунктындагы «а» һәм (яки) «б» пунктчаларында күрсәтелгән авыл хуҗалыгы культуралары орлыкларын

чәчелгән җир кишәрлекләреннән файдалану хокуклары булуын раслый торган документлар;

әлеге Тәртипнең 1 пунктындагы «а» пунктчасында күрсәтелгән юнәлеш буенча:

субсидия алучылар тарафыннан Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрнең дәүләт реестрын алып бару тәртибе турында» 2023 елның 2 февралендәге 154 номерлы карары белән расланган Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрнең дәүләт реестрын алып бару кагыйдәләренә 1 нче кушымтаның 1, 2, 5, 14, 17, 18 һәм 20 пунктлары нигезендә белешмәләр бирү.»;

13 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«13. Каплау өчен субсидия бирелә торган чыгымнар юнәлешләре:

әлеге Тәртипнең 1 пунктындагы «а» пунктчасында күрсәтелгән авыл хуҗалыгы культуралары орлыкларын сатып алу өчен агымдагы финанс елының һәм (яки) үткән финанс елының өстәлгән кыйммәткә салым түләү чыгымнарын тотып калып исәпләнгән чыгымнары;

әлеге Тәртипнең 1 пунктындагы «б» пунктчасында күрсәтелгән авыл хуҗалыгы культуралары орлыкларын сатып алу өчен агымдагы финанс елының һәм (яки) үткән финанс елының өстәлгән кыйммәткә салым түләү чыгымнарын тотып калып исәпләнгән чыгымнары.»;

14 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«14. Субсидия алучыга бирелә торган субсидия күләме:

әлеге Тәртипнең 1 пунктындагы «а» пунктчасы нигезендә ($W_{эс}$) (сумда) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$W_{эс} = P_{эс} \times \left(C \times \frac{N}{1\,000}\right) \times S \times K_{согл},$$

монда:

$P_{эс}$ – агымдагы финанс елында әлеге Тәртипнең 1 пунктындагы «а» пунктчасында күрсәтелгән авыл хуҗалыгы культуралары орлыклары утыртылган, орлык чәчүлекләрен апробацияләү актлары белән расланган чәчү мәйданы, гектар;

C – әлеге Тәртипнең 1 пунктындагы «а» пунктчасында күрсәтелгән, сатып алынган, агымдагы финанс елы уңышын чәчү өчен файдаланылган авыл хуҗалыгы культуралары орлыкларының кыйммәте (өстәлгән кыйммәткә салымны исәпкә алмыйча), 1 тоннага сум;

N – орлык чәчүлекләрен апробацияләү актларында чагылдырылган, әлеге Тәртипнең 1 пунктындагы «а» пунктчасында күрсәтелгән авыл хуҗалыгы культуралары орлыкларын чәчү нормасы, 1 гектарга килограмм;

S – Министрлык боерыгы белән раслана торган субсидия ставкасы, процент;

$K_{согл}$ – ставкага карата кулланыла торган коэффициент:

хисап финанс елында субсидия алучы тарафыннан әлеге Тәртипнең 15 пунктындагы икенче абзацында каралган субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешелгәндә, ставкага карата хисап елы өчен факттагы күрсәткечкә тигез күләмдә, әмма иң күбе 1,2 булган коэффициент кулланыла;

хисап финанс елында субсидия алучы тарафыннан әлеге Тәртипнең 15 пунктындагы икенче абзацында каралган субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешелмәгәндә, ставкага карата хисап елы өчен фактагы күрсәткечкә тигез күләмдә, әмма кимендә 0,8 булган коэффициент кулланыла.

Субсидия алучыга бирелә торган субсидия күләме агымдагы финанс елында һәм (яки) үткән финанс елында әлеге Тәртипнең 1 пунктындагы «а» пунктчасында күрсәтелгән авыл хуҗалыгы культураларының агымдагы ел уңышын утырту өчен кулланылган орлыкларын сатып алуга тотылган фактагы чыгымнардан арттыра алмый;

әлеге Тәртипнең 1 пунктындагы «б» пунктчасы нигезендә (Wc) (сумда) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$W_с = Z_с \times 70\% \times К_{согл},$$

монда:

$Z_с$ – әлеге Тәртипнең 1 пунктындагы «б» пунктчасында күрсәтелгән авыл хуҗалыгы культуралары орлыкларын сатып алу өчен агымдагы финанс елында һәм (яки) агымдагы финанс елына кадәрге елда фактта тотылган чыгымнарның мондый орлыкларны реализацияләүнең иң чик кыйммәтеннән артмый торган суммасы, сум.

Әлеге Тәртипнең 1 пунктындагы «б» пунктчасында күрсәтелгән авыл хуҗалыгы культуралары орлыкларының иң чик кыйммәте бер чәчү берәмлеге өчен 15,0 мең сум тәшкил итә;

70% – субсидия ставкасы;

$К_{согл}$ – ставкага карата кулланыла торган коэффициент:

хисап финанс елында субсидия алучы тарафыннан әлеге Тәртипнең 15 пунктындагы өченче абзацында каралган субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешелгәндә, ставкага карата хисап елы өчен фактагы күрсәткечкә тигез күләмдә, әмма иң күбе 1,2 булган коэффициент кулланыла;

хисап финанс елында субсидия алучы тарафыннан әлеге Тәртипнең 15 пунктындагы өченче абзацында каралган субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешелмәгәндә, ставкага карата хисап елы өчен фактагы күрсәткечкә тигез күләмдә, әмма кимендә 0,8 булган коэффициент кулланыла.

Әгәр субсидия алучылар тарафыннан белдерелгән субсидия бирүгә ихтыяҗның гомуми күләме әлеге Тәртипнең 4 пунктында күрсәтелгән, җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары күләменнән артып китсә, субсидия алучыга бирелергә тиешле субсидия суммасы Министрлык тарафыннан түбәндәге формулалар буенча билгеләнә:

әлеге тәртипнең 1 пунктындагы «а» пунктчасы нигезендә ($W_{кэс}$):

$$W_{кэс} = W_{эс} \times К,$$

әлеге тәртипнең 1 пунктындагы «б» пунктчасы нигезендә ($W_{кс}$):

$$W_{кс} = W_с \times К,$$

монда K – түбәндәге формула буенча билгеләнә торган төзәтү коэффициенты:

$$K = \frac{V}{\left(\sum_{i=1}^{n} W_{эс(i)} + \sum_{i=1}^{h} W_{c(i)}\right)} \leq 1,$$

монда:

V – әлеге Тәртипнең 4 пунктында күрсәтелгән, җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары күләме;

n – әлеге Тәртипнең 1 пунктындагы «а» пунктчасы нигезендә субсидия алучылар саны;

h – әлеге Тәртипнең 1 пунктындагы «б» пунктчасы нигезендә субсидия алучылар саны.»;

15 пунктта:

икенче абзац:

«орлыклар» сүзеннән соң «авыл хуҗалыгы культуралары» сүзләрен өстәргә, татар текстында «орлыклар» сүзен «орлыклары» сүзенә алмаштырырга;

татар текстында «31 декабрьгә» сүзләрен «агымдагы елның 31 декабренә» сүзләренә алмаштырырга;

өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге Тәртипнең 1 пунктындагы «б» пунктчасы нигезендә – агымдагы елның 31 декабренә карата агымдагы һәм (яки) үткән елда ФФТП кысаларында булдырылган авыл хуҗалыгы культуралары сортларының һәм (яки) гибридларының орлыклары (бәрәңге һәм яшелчә культуралары орлыкларыннан тыш) (тонна) сатып алынды һәм чәчелде.»;

25 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«25. Сайлап алуда катнашучы сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүдә күрсәтелгән срокларда заявканы «Электрон бюджет» системасының веб-интерфейсның тиешле экран формаларын тутыру юлы белән электрон рәвештә төзи һәм бирә һәм «Электрон бюджет» системасына документларның электрон күчермәләрен (сканлаштыру юлы белән электрон формага үзгәртелгән кәгазь чыганактагы документларны) тапшыра:

Министрлык боерыгы белән расланган формалар буенча бирелергә тиешле субсидия турында исәп-хисап белешмә кәгазе;

әлеге Тәртипнең 1 пунктындагы «а» һәм (яки) «б» пунктчаларында күрсәтелгән авыл хуҗалыгы культуралары орлыклары өчен түләүне раслый торган кайтарту (сату-сатып алу) шартнамәләре, универсаль тапшыру документлары (УПД), һәм (яки) товар-транспорт йөкнамәләре, һәм (яки) товар йөкнамәләре (ТОРГ-12 номерлы унификацияләнгән форма);

сертификат биргән орган тарафыннан таныкланган яраклылык сертификаты һәм (яки) яраклылык сертификаты күчермәсе һәм (яки) әлеге Тәртипнең 1 пунктындагы «а» һәм (яки) «б» пунктчаларында күрсәтелгән авыл хуҗалыгы культуралары орлыкларының чәчү сыйфатларын сынау беркетмәләре һәм (яки) инспекцияләү беркетмәләре;

карантин сертификаты һәм фитосанитар контроль акты (әлеге Тәртипнең 1 пунктындагы «а» һәм (яки) «б» пунктчаларында күрсәтелгән авыл хуҗалыгы

культуралары орлыкларын Татарстан Республикасы чикләреннән карантин зоналарыннан кертелгәндә) һәм (яки) аккредитацияләнгән лабораториядән карантиндагы продукциянең карантин фитосанитар хәле турында бәяләмә күчермәләре (әлеге Тәртипнең 1 пунктындагы «а» һәм (яки) «б» пунктчаларында күрсәтелгән авыл хуҗалыгы культуралары орлыкларын Татарстан Республикасы чикләреннән карантин булмаган зоналардан кертелгәндә);

агымдагы финанс елында һәм (яки) үткән финанс елында әлеге Тәртипнең 1 пунктындагы «а» һәм (яки) «б» пунктчаларында күрсәтелгән, агымдагы ел уңышын чәчүгә файдаланылган авыл хуҗалыгы культуралары орлыкларын сатып алу өчен субсидия алучы тарафыннан тотылган факттагы чыгымнар турында һәм бухгалтерлык исәбе мәгълүматлары буенча мондый авыл хуҗалыгы культуралары орлыкларының 1 тоннасы кыйммәте турында белешмә кәгазе;

агымдагы финанс елында һәм (яки) үткән финанс елында төзелгән агымдагы елда әлеге Тәртипнең 1 пунктындагы «а» һәм (яки) «б» пунктчаларында күрсәтелгән авыл хуҗалыгы культуралары уңышын югалту (уңышы юкка чыгу) очрагына авыл хуҗалыгы иминияте шартнамәләре нигезендә иминләштерелгән чәчү мәйданнары күләме турында ирекле форма мәгълүмат;

салым түләүченең өстәлгән кыйммәткә салым исәпләүгә һәм түләүгә бәйле йөкләмәләрен үтәүдән азат итү хокукыннан файдаланучы сайлап алуда катнашучыларның өчен салым салуның кулланыла торган системасы турында салым органыннан белешмәләр;

әлеге Тәртипнең 1 пунктындагы «а» һәм (яки) «б» пунктчаларында күрсәтелгән авыл хуҗалыгы культуралары орлыклары чәчелгән җир кишәрлекләреннән файдалану хокукына ирекле форма документлар реестры (Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрыннан күчемсез мөлкәт объектының төп характеристикалары һәм аларга карата теркәлгән хокуклар турында өземтәләр, әгәр җир кишәрлеге кыска сроклы арендага яки субарендага бирелгән булса, аренда, субаренда шартнамәләре (килешүләре));

Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы ведомствосы буйсынуында булган, сайлап алуда катнашучы эшчәнлек гамәлгә ашырган мелиорация өлкәсендәге федераль дәүләт бюджет учреждениесенең әлеге учреждениегә сайлап алуда катнашучының су бирү (чыгару) хезмәтләре өчен үз вакытында түләнмәгән бурычы һәм (яки) әлеге учреждениенең суд тарафыннан эшкә алынган субсидия алучыдан су бирү (чыгару) хезмәтләре күрсәтү шартнамәсе буенча 50 мең сумнан арткан күләмдә бурыч акчасын түләтү турында дәгъва гаризасы булмау хакында белешмә кәгазе (әлеге белешмә кәгазе булмаса, Министрлык аны мөстәкыйль рәвештә соратып ала);

әлеге Тәртипнең 1 пунктындагы «а» пунктчасында күрсәтелгән юнәлеш буенча сайлап алуда катнашучы түбәндәге электрон күчермәләрне өстәмә рәвештә тапшыра:

«Россия авыл хуҗалыгы үзәге» федераль дәүләт бюджет учреждениесенең Татарстан Республикасы буенча филиалы тарафыннан таныкланган агымдагы ел уңышы өчен әлеге Тәртипнең 1 пунктындагы «а» пунктчасында күрсәтелгән авыл хуҗалыгы культураларының орлык чәчүлекләрен апробацияләү актлары;

Министрлык боерыгы белән расланган форма буенча әлеге Тәртипнең 1 пунктындагы «а» пунктчасында күрсәтелгән авыл хуҗалыгы культуралары орлыкларын чәчелгән, авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрнең дәүләт реестрына кертелгән җир кишәрлекләре паспортлары реестры;

әлеге Тәртипнең 1 пунктындагы «б» пунктчасында күрсәтелгән юнәлеш буенча сайлап алуда катнашучы Министрлык боерыгы белән расланган форма нигезендә әлеге Тәртипнең 1 пунктындагы «б» пунктчасында күрсәтелгән авыл хуҗалыгы культуралары орлыкларын чәчүгә тотылуны раслый торган бухгалтерлык исәбе мәгълүматлары буенча төзелгән белешмә кәгазенең электрон күчермәсен өстәмә рәвештә тапшыра.»;

55 пунктның икенче абзацында «исәп-хисап яки корреспондент» сүзләрен төшереп калдырырга;

60 пунктта татар текстында «Бирелгән субсидия» сүзләрен «Субсидия акчасы» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Культуртехника, агроурманмелиорация һәм гидромелиорация чараларын үткәрүгә бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджеттан финанслаша торган субсидия бирү тәртибендә:

2 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«мелиорация проектларын гамәлгә ашыру чыгымнары – Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрне нәтиҗәле әйләнешкә кертү һәм Россия Федерациясе мелиорация комплексын үстерү буенча дәүләт программасы турында» 2021 елның 14 маендагы 731 номерлы карары белән расланган Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрне нәтиҗәле әйләнешкә кертү һәм Россия Федерациясе мелиорация комплексын үстерү буенча дәүләт программасының 6 нчы һәм 8 нче кушымталары, әлеге Тәртип һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Аерым юнәлешләр буенча агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме чаралары турында» 2021 ел, 30 июнь, 514 нче карары белән расланган «Агросәнәгать комплексы продукциясен экспортлау» федераль проекты кысаларында чыгымнарның бер өлешен каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджеттан финанслаша торган субсидия бирү тәртибе кысаларында мелиорация проектларын гамәлгә ашыру чыгымнары элегрәк капланмау шарты белән субсидия бирелгән елда һәм (яки) субсидия бирелгән елга кадәрге ике ел өчен, өстәлгән кыйммәткә салымны исәпкә алмыйча, фактта тотылган, документлар белән расланган акчалата рәвештәге чыгымнар (аванс түләнгән сату-сатып алу, товарлар кайтарту, эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү шартнамәләре буенча тулысынча яки өлешчә түләүне кертеп). Аванс түләнгән сату-сатып алу, товарлар кайтарту, эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү шартнамәләре буенча тулысынча яки өлешчә түләү гамәлгә ашырылган очракта, фактта тотылган чыгымнар датасы булып товарлар тапшыру, товарлар кайтарту, эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү датасы санала;»;

5 пунктта:

«Бюджет» бүлегендә» сүзләрен «(бердәм портал бүлегендә)» сүзләренә алмаштырырга;

татар текстында «мәгълүмат» сүзеннән соң «субсидия бирү өчен бюджет ассигнованиеләре Министрлыкка җиткерелгән көннән соң килә торган көннән алып 10 эш көне эчендә» сүзләрен өстәргә;

111 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Җирләрне мелиорацияләү турында» 1996 елның 10 гыйнварындагы 4-ФЗ номерлы Федераль законның $20^1$ статьясы нигезендә мелиорация проекты гамәлгә ашырылган җир кишәрлекләрендә урнашкан агроурманмелиорация утыртмалары турында белешмәләр бирү.»;

13 пунктның өченче абзацында «мелиорация җайланмасы һәм (яки) техника» сүзләрен «төзелеш, реконструкция һәм техник яктан яңадан җиһазландыру кыйммәтенең җыелма смета исәп-хисабына кертелгән машиналар, җайланмалар, яңгыр һәм су сиптерү аппаратлары, насос станцияләре» сүзләренә алмаштырырга;

14 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«14. Субсидия алучыга түбәндәгеләр нигезендә бирелә торган субсидия күләме:

әлеге Тәртипнең 1 пунктындагы «а» пунктчасы нигезендә ($W_k$) (сумда) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$W_k = (P_k \times 50\%) + (P_{пk} \times 50\%),$$

монда:

$P_k$ – субсидия бирелгән елда һәм (яки) субсидия бирелгән елга кадәрге ике ел өчен КС-2 номерлы форма буенча башкарылган эшләрне кабул итү турындагы актларга кертелгән төзелеш, монтаж һәм башка төрләр эшләренә культуртехник чаралар буенча тотылган фактагы чыгымнар (өстәлгән кыйммәткә салым түләү чыгымнарын тотып калып), сум;

$P_{пk}$ – субсидия бирелгән елда һәм (яки) субсидия бирелгән елга кадәрге ике ел өчен проект-смета документациясен эшләүгә культуртехник чаралар буенча тотылган, мелиорация проектын гамәлгә ашыру чыгымнарының иң күбе 5 процентын тәшкил итә торган фактагы чыгымнар (өстәлгән кыйммәткә салым түләү чыгымнарын тотып калып), сум;

әлеге Тәртипнең 1 пунктындагы «б» пунктчасы нигезендә ($W_a$) (сумда) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$W_a = (P_a \times 90\%) + (P_{па} \times 90\%),$$

монда:

$P_a$ – субсидия бирелгән елда һәм (яки) субсидия бирелгән елга кадәрге ике ел өчен КС-2 номерлы форма буенча башкарылган эшләрне кабул итү турындагы актларга кертелгән төзелеш, монтаж һәм башка төрләр эшләренә агроурманмелиорация чаралары буенча тотылган фактагы чыгымнар (өстәлгән кыйммәткә салым түләү чыгымнарын тотып калып), сум;

$P_{па}$ – субсидия бирелгән елда һәм (яки) субсидия бирелгән елга кадәрге ике ел өчен проект-смета документациясен эшләүгә агроурманмелиорация чаралары буенча тотылган, мелиорация проектын гамәлгә ашыру чыгымнарының иң күбе 5 процентын тәшкил итә торган фактагы чыгымнар (өстәлгән кыйммәткә салым түләү чыгымнарын тотып калып), сум;

әлеге Тәртипнең 1 пунктындагы «в» пунктчасы нигезендә ($W_г$) (сумда) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$W_г = (P_г \times 50\%) + (P_{пг} \times 50\%) + (P_{мт} \times П),$$

монда:

$P_г$ – субсидия бирелгән елда һәм (яки) субсидия бирелгән елга кадәрге ике ел өчен КС-2 номерлы форма буенча башкарылган эшләрне кабул итү турындагы актларга кертелгән төзелеш, монтаж һәм башка төрләр эшләренә гидромелиорация чаралары буенча тотылган факттагы чыгымнар (өстәлгән кыйммәткә салым түләү чыгымнарын тотып калып), сум;

$P_{пг}$ – субсидия бирелгән елда һәм (яки) субсидия бирелгән елга кадәрге ике ел өчен проект-смета документациясен эшләүгә гидромелиорация чаралары буенча тотылган, мелиорация проектын гамәлгә ашыру чыгымнарының иң күбе 5 процентын тәшкил итә торган факттагы чыгымнар (өстәлгән кыйммәткә салым түләү чыгымнарын тотып калып), сум;

$P_{мт}$ – субсидия бирелгән елда һәм (яки) субсидия бирелгән елга кадәрге ике ел өчен төзелеш, реконструкция һәм техник яктан яңадан җиһазландыру кыйммәтенең җыелма смета исәп-хисабына кертелгән машиналар, җайланмалар, яңгыр яудыру һәм су сиптерү аппаратлары, насос станцияләре сатып алуга гидромелиорация чаралары буенча факттагы чыгымнар (өстәлгән кыйммәткә салым түләү чыгымнарын тотып калып), сум;

П – төзелеш, реконструкция һәм техник яктан яңадан җиһазландыру кыйммәтенең җыелма смета исәп-хисабына кертелгән машиналар, җайланмалар, яңгыр яудыру һәм су сиптерү аппаратлары, насос станцияләре сатып алуга факттагы чыгымнарны каплау проценты түбәндәгечә тәшкил итә:

а) 2027 елның 1 гыйнварына кадәр:

Россия Федерациясе һәм (яки) Беларусь Республикасы территорияләрендә җитештерелүе расланган киң колачлы яңгыр яудыру машиналары һәм барабан тибындагы яңгыр яудыру машиналары кыйммәтенең 50 процентын;

Россия Федерациясе һәм (яки) Беларусь Республикасы территорияләреннән читтә җитештерелгән киң колачлы яңгыр яудыру машиналары һәм барабан тибындагы яңгыр яудыру машиналары кыйммәтенең 25 процентын;

төзелеш, реконструкция һәм техник яктан яңадан җиһазландыру кыйммәтенең җыелма смета исәп-хисабына кертелгән машиналар, җайланмалар, яңгыр яудыру һәм су сиптерү аппаратлары, насос станцияләре (киң колачлы яңгыр яудыру машиналарыннан һәм барабан тибындагы яңгыр яудыру машиналарыннан тыш) кыйммәтенең 50 процентын;

б) 2027 елның 1 гыйнварыннан:

Россия Федерациясе һәм (яки) Беларусь Республикасы территорияләрендә җитештерелүе расланган киң колачлы яңгыр яудыру машиналары һәм барабан тибындагы яңгыр яудыру машиналары кыйммәтенең 50 процентын;

төзелеш, реконструкция һәм техник яктан яңадан җиһазландыру кыйммәтенең җыелма смета исәп-хисабына кертелгән машиналар, җайланмалар, яңгыр яудыру һәм су сиптерү аппаратлары, насос станцияләре (киң колачлы яңгыр яудыру машиналарыннан һәм барабан тибындагы яңгыр яудыру машиналарыннан тыш) кыйммәтенең 50 процентын.

Әлеге Тәртипнең 1 пунктында каралган чаралар буенча субсидия исәпләгәндә кулланыла торган чыгымнар күләме Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан билгеләнә торган 1 гектар җир мәйданы өчен эшләр кыйммәтенең иң чик күләмен исәпкә алып исәпләп чыгарылган эшләр кыйммәтенең иң чик күләменнән артып китә алмый.

Әгәр тиешле җирләрнең 1 гектар мәйданы өчен эшләр кыйммәте алар буенча билгеләнгән иң чик кыйммәттән кимрәк булса, исәпләп чыгарганда авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләр тарафыннан белдерелгән 1 гектар мәйданда үткәрелә торган эшләр кыйммәте кулланыла.»;

25 пунктта:

өченче абзацта «мелиорация җайланмасы» сүзләрен «төзелеш, реконструкция һәм техник яктан яңадан җиһазландыру кыйммәтенең җыелма смета исәп-хисабына кертелгән машиналар, җайланмалар, яңгыр яудыру һәм су сиптерү аппаратлары, насос станцияләре,» сүзләренә алмаштырырга;

җиденче абзацка «, Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан расланган форма буенча мелиорация проекты тормышка ашырылган җир кишәрлекләрендә урнашкан агроурманмелиорация утыртмалары турында белешмәләр» сүзләрен өстәргә;

55 пунктта «исәп-хисап яки корреспондент» сүзләрен төшереп калдырырга;

60 пунктта татар текстында «Бирелгән субсидия» сүзләрен «Субсидия акчасы» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Җирләрне химик мелиорацияләү чараларын үткәрүгә бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджеттан финанслаша торган субсидия бирү тәртибендә:

3 пунктта:

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«химик мелиорация проектларын гамәлгә ашыру чыгымнары – субсидия бирелгән елда һәм (яки) субсидия бирелгән елга кадәрге ике ел өчен, өстәлгән кыйммәткә салымны исәпкә алмыйча, фактта тотылган, документлар белән расланган акчалата рәвештәге чыгымнар (химик мелиорация проектларын гамәлгә ашыру чыгымнары башка норматив хокукый актлар нигезендә элегрәк капланмау шарты белән аванс түләнгән сату-сатып алу, товарлар кайтарту, эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү шартнамәләре буенча тулысынча яки өлешчә түләүне кертеп). Аванс түләнгән сату-сатып алу, товарлар кайтарту, эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү шартнамәләре буенча тулысынча яки өлешчә түләү гамәлгә ашырылган очракта, фактта тотылган чыгымнар датасы булып товарлар тапшыру, товарлар кайтарту, эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү датасы санала.»;

6 пунктта:

«Бюджет» бүлегендә» сүзләрен «(бердәм портал бүлегендә)» сүзләренә алмаштырырга;

татар текстында «мәгълүмат» сүзеннән соң «субсидия бирү өчен бюджет ассигнованиеләре Министрлыкка җиткерелгән көннән соң килә торган көннән алып 10 эш көне эчендә» сүзләрен өстәргә;

111 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Җирләрне мелиорацияләү турында» 1996 елның 10 гыйнварындагы 4-ФЗ номерлы Федераль законның 20[1] статьясы нигезендә химик мелиорация проекты гамәлгә ашырылган җир кишәрлекләрендә урнашкан агроурманмелиорация утыртмалары турында белешмәләр бирү.»;

25 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан расланган форма буенча химик мелиорация проекты гамәлгә ашырылган җир кишәрлекләрендә урнашкан агроурманмелиорация утыртмалары турында белешмәләр.»;

55 пунктның икенче абзацында «исәп-хисап яки корреспондент» сүзләрен төшереп калдырырга;

60 пунктта татар текстында «Бирелгән субсидия» сүзләрен «Субсидия акчасы» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Авыл хуҗалыгы иминиятенә ярдәм күрсәтү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджеттан финанслаша торган субсидия бирү тәртибендә:

5 пунктта:

«Бюджет» бүлегендә» сүзләрен «(бердәм портал бүлегендә)» сүзләренә алмаштырырга;

татар текстында «мәгълүмат» сүзеннән соң «субсидия бирү өчен бюджет ассигнованиеләре Министрлыкка җиткерелгән көннән соң килә торган көннән алып 10 эш көне эчендә» сүзләрен өстәргә;

11 пунктта:

сигезенче абзацта татар текстында «административ җаваплылыкка» сүзләре алдына «субсидия алучыларны (вазыйфаи һәм юридик затларны)» сүзләрен өстәргә;

унынчы һәм уникенче абзацлар үз көчен югалткан дип танырга;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«авыл хуҗалыгы терлекләрен авыл хуҗалыгы иминләштерү шартнамәсенә Россия Федерациясе Граждан кодексының 965 статьясы нигезендә иминләштерүченең Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән зыян каплау таләбе хокукы иминләштерүчегә күчми торган шарт кертү.»;

15 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге Тәртипнең 2 пунктындагы «а» пунктчасы нигезендә – субсидия бирү елының 31 декабренә карата авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләр тарафыннан агымдагы елның һәм (яки) субсидия бирелгән елдан соң килә торган елның уңышы өчен күпьеллык үсентеләр утырту мәйданы һәм (яки) чәчү (утырту) мәйданы иминиятләштерелгән;»;

25 пунктның унөченче һәм ундүртенче абзацлары үз көчен югалткан дип танырга;

55 пунктта «исәп-хисап яки корреспондент» сүзләрен төшереп калдырырга;

60 пунктта татар текстында «Бирелгән субсидия» сүзләрен «Субсидия акчасы» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Сөт җитештерүгә ярдәм күрсәтү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджеттан финанслаша торган субсидия бирү тәртибендә:

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Субсидия «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә кече һәм урта эшкуарлык субъектларының бердәм реестрына кертелгән, кече эшкуарлык субъектлары, шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы һәм «Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын кулланучы гражданнар, фәнни һәм мәгариф оешмалары өчен Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән иң чик күрсәткеченнән кереме артмаган авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә (шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнардан һәм авыл хуҗалыгы кредит кулланучылар кооперативларыннан тыш) (алга таба – сайлап алуда катнашучылар) бирелә.»;

5 пунктта:

«Бюджет» бүлегендә» сүзләрен «(бердәм портал бүлегендә)» сүзләренә алмаштырырга;

татар текстында «мәгълүмат» сүзеннән соң «субсидия бирү өчен бюджет ассигнованиеләре Министрлыкка җиткерелгән көннән соң килә торган көннән алып 10 эш көне эчендә» сүзләрен өстәргә;

11 пунктта:

җиденче абзацта татар текстында «административ җаваплылыкка» сүзләре алдына «субсидия алучыларны (вазыйфаи һәм юридик затларны)» сүзләрен өстәргә;

унынчы абзацта татар текстында «кимендә» сүзе үзгәрешсез кала;

унөченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«субсидияләр алучылар Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрнең дәүләт реестрын алып бару тәртибе турында» 2023 елның 2 февралендәге 154 номерлы карары белән расланган Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрнең дәүләт реестрын алып бару кагыйдәләренә 1 нче кушымтаның 1, 2, 11 һәм 14 пунктлары нигезендә терлекчелек продукциясен җитештерү өчен кирәкле терлекчелек комплекслары (фермалары) урнашкан җир кишәрлекләре турында белешмәләр бирү.»;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Хайваннарны исәпкә алуны гамәлгә ашыру кагыйдәләрен, индивидуаль яки төркемләп тамга ясалырга һәм исәпкә алынырга тиешле хайваннарның төрләре, хайваннарга индивидуаль яки төркемләп тамга ясауны һәм аларны исәпкә алуны гамәлгә ашыру очраклары, шулай ук хайваннарны исәпкә алуны гамәлгә ашыру сроклары исемлеген раслау турында» 2023 елның 5 апрелендәге 550 нче карары белән расланган Хайваннарны исәпкә алуны гамәлгә ашыру кагыйдәләре нигезендә Ветеринария өлкәсендә федераль дәүләт мәгълүмат системасында хайваннарга индивидуаль яки төркемләп тамга ясау һәм аларны исәпкә алу турында мәгълүматлар белән расланган авыл хуҗалыгы хайваннарының баш саны булу.»;

14 пунктның егерменче абзацы үз көчен югалткан дип танырга;

25 пунктта:

унынчы абзацта татар текстында «хайваннар» сүзе алдына «агымдагы финанс елында» сүзләрен өстәргә;

унберенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Министрлык боерыгы белән расланган форма буенча агымдагы финанс елында терлекчелек продукциясен җитештерү өчен кирәкле терлекчелек комплекслары (фермалары) урнашкан җир кишәрлекләре паспортлары реестры;»;

түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Ветеринария өлкәсендә федераль дәүләт мәгълүмат системасында («Хорриот» ФДМС) теркәлгән мөгезле эре терлек һәм кәҗәләрнең баш саны турында Татарстан Республикасының район дәүләт ветеринария берләшмәсе тарафыннан бирелгән белешмә кәгазе;

хисап елында кече эшкуарлык субъектлары өчен Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән иң чик күрсәткечтән артмаган керем күләмен раслау өчен сайлап алуда катнашучылар түбәндәге документларның электрон күчермәләрен өстәмә рәвештә тапшыра:

салым салуның гадиләштерелгән системасындагы яки бердәм авыл хуҗалыгы салымындагы оешмалар һәм крестьян (фермер) хуҗалыклары – салым декларациясе яки керемнәрне һәм чыгымнарны исәпкә алу кенәгәләре;

салым салуның гомуми системасындагы оешмалар һәм индивидуаль эшкуарлар – физик затлар табышына салым яки керемнәренә салым буенча декларацияләр (3-НДФЛ).»;

56 пунктның икенче абзацында «исәп-хисап яки корреспондент» сүзләрен төшереп калдырырга;

61 пунктта татар текстында «Бирелгән субсидия» сүзләрен «Субсидия акчасы» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Нәселле терлекчелеккә ярдәм күрсәтү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджеттан финанслаша торган субсидия бирү тәртибендә:

исемендә татар текстында «терлекчелеккә ярдәм күрсәтү» сүзләреннән соң «һәм авыл хуҗалыгы хайваннарының нәселле яшь терлеген сатып алу» сүзләрен өстәргә;

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Әлеге Тәртип түбәндәге юнәлешләр буенча нәселле терлекчелеккә ярдәм итү һәм авыл хуҗалыгы хайваннарының нәселле яшь терлеген сатып алу чыгымнарының бер өлешен (өстәлгән кыйммәткә салым түләү чыгымнарын тотып калып) каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджеттан финанслаша торган субсидия (алга таба – субсидия) бирү шартларын һәм тәртибен билгели:

а) хисап финанс елындагы авыл хуҗалыгы хайваннарының нәселле ана баш санын (мөгезле эре терлекнең нәселле ана баш саныннан тыш) асрауга бәйле чыгымнарының бер өлешен каплауга;

б) хисап финанс елындагы нәсел токымының сыйфаты буенча бәяләнгән яки әлеге сыйфатны бәяләү процессында булган нәселле үгезләрне асрауга бәйле чыгымнарының бер өлешен каплауга;

в) хисап һәм (яки) агымдагы финанс елларындагы дәүләт нәсел регистрында теркәлгән нәсел хуҗалыкларында сөт һәм ит бирә торган мөгезле эре терлекнең нәселле терлеген сатып алуга бәйле чыгымнарының бер өлешен каплауга. Шул ук вакытта сөт бирә торган нәселле таналарның субсидияләнә торган баш санының нәтиҗәле орлыкландыру яше 16 айдан да артмаска тиеш.

г) Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан раслана торган исемлек нигезендә хисап финанс елындагы мөгезле эре терлекнең нәселле ана баш санына карата селекция чараларын үткәрүгә бәйле чыгымнарның бер өлешен каплауга.

Субсидия түбәндәгеләр өчен бирелә:

Министрлык тарафыннан Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы белән килештереп раслана торган нәсел хуҗалыклары исемлегенә кертелгән авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә (шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнардан һәм авыл хуҗалыгы кредит кулланучылар кооперативларыннан тыш), фәнни һәм мәгариф оешмаларына «а», «б» һәм «г» пунктларында күрсәтелгән юнәлешләр буенча;

авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә (шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнардан һәм авыл хуҗалыгы кредит кулланучылар кооперативларыннан тыш), фәнни һәм мәгариф оешмаларына «в» пунктчасында күрсәтелгән юнәлеш буенча.

Өстәлгән кыйммәткә салым исәпләүгә һәм түләүгә бәйле салым түләүче вазыйфаларын үтәүдән азат итү хокукыннан файдалана торган субсидия алучылар өчен чыгымнарның бер өлешен каплау, өстәлгән кыйммәткә салым суммасын кертеп, әлеге пунктта күрсәтелгән максатларга чыгымнар суммасыннан чыгып гамәлгә ашырыла.»;

4 пунктта:

«Бюджет» бүлегендә» сүзләрен «(бердәм портал бүлегендә)» сүзләренә алмаштырырга;

татар текстында «мәгълүмат» сүзеннән соң «субсидия бирү өчен бюджет ассигнованиеләре Министрлыкка җиткерелгән көннән соң килә торган көннән алып 10 эш көне эчендә» сүзләрен өстәргә;

10 пунктта:

өченче абзацта татар текстында «административ җаваплылыкка» сүзләре алдына «субсидия алучыларны (вазыйфаи һәм юридик затларны)» сүзләрен өстәргә;

җиденче абзац үз көчен югалткан дип танырга;

түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«әлеге Тәртипнең 1 пунктындагы «а», «б», «г» пунктчалары нигезендә:

акча алучылар Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрнең дәүләт реестрын алып бару тәртибе турында» 2023 елның 2 февралендәге 154 номерлы карары белән расланган Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрнең дәүләт реестрын алып бару кагыйдәләренә 1 нче кушымтаның 1, 2, 11 һәм 14 пунктлары нигезендә терлекчелек продукциясен җитештерү өчен кирәкле терлекчелек комплекслары (фермалары) урнашкан җир кишәрлекләре турында белешмәләр бирү.»;

12 пунктта:

икенче абзацта татар текстында «авыл хуҗалыгы хайваннарының нәселле ана баш санын» сүзләреннән соң «(мөгезле эре терлекнең нәселле ана баш санынннан тыш)» сүзләренә өстәргә;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«әлеге Тәртипнең 1 пунктындагы «г» пунктчасы нигезендә – Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан раслана торган исемлек нигезендә мөгезле эре терлекнең нәселле ана баш санына карата селекция чараларын үткәрү чыгымнары.»;

13 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«13. Әлеге Тәртип нигезендә субсидия алучыга бирелә торган субсидия күләме түбәндәге формулалар буенча билгеләнә:

а) әлеге Тәртипнең 1 пунктындагы «а» пунктчасы нигезендә ($W_1$) (сумда) – түбәндәге формула буенча:

$$W_1 = P_1 \times K \times S_1 \times K_{согл} + P_2 \times K \times S_2 \times K_{согл} + P_3 \times K \times S_3 \times K_{согл} + P_4 \times K \times S_4 \times \times K_{согл} + P_5 \times K \times S_5 \times K_{согл},$$

монда:

$P_1$ – агымдагы финанс елының 1 гыйнварына карата субсидия алучыда булган йонлы җәнлекләрнең нәселле ана баш саны, баш;

K – Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан хайваннарның тиешле төрләре буенча билгеләнә торган авыл хуҗалыгы терлекләренең нәселле баш санын шартлы башларга күчерү коэффициенты;

$S_1$ – йонлы җәнлекләрнең нәселле ана баш санының 1 шартлы башына 2 400,0 сум күләмендә субсидия ставкасы;

$K_{согл}$ – ставкага карата кулланыла торган коэффициент:

хисап финанс елында субсидия алучы тарафыннан әлеге Тәртипнең 15 пунктындагы икенче абзацында каралган субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешелгәндә, ставкага карата хисап елы өчен факттагы күрсәткечкә тигез күләмдә, әмма иң күбе 1,2 булган коэффициент кулланыла;

хисап финанс елында субсидия алучы тарафыннан әлеге Тәртипнең 15 пунктындагы икенче абзацында каралган субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешелмәгәндә, ставкага карата хисап елы өчен факттагы күрсәткечкә тигез күләмдә, әмма кимендә 0,8 булган коэффициент кулланыла;

$P_2$ – агымдагы финанс елының 1 гыйнварына карата субсидия алучыда булган кош-кортларның нәселле ана баш саны, баш;

$S_2$ – кош-кортларның нәселле ана баш санының 1 шартлы башына 1 300,0 сум күләмендә субсидия ставкасы;

$P_3$ – агымдагы финанс елының 1 гыйнварына карата субсидия алучыда булган сарыкларның нәселле ана баш саны, баш;

$S_3$ – сарыкларның нәселле ана баш санының 1 шартлы башына 30 000,0 сум күләмендә субсидия ставкасы;

$P_4$ – агымдагы финанс елының 1 гыйнварына карата субсидия алучыда булган кәҗәләрнең нәселле ана баш саны, баш;

$S_4$ – кәҗәләрнең нәселле ана баш санының 1 шартлы башына 5 400,0 сум күләмендә субсидия ставкасы;

$P_5$ – агымдагы финанс елының 1 гыйнварына карата субсидия алучыда булган атларның нәселле ана баш саны, баш;

$S_5$ – атларның нәселле ана баш санының 1 шартлы башына 15 000,0 сум күләмендә субсидия ставкасы.

Шул ук вакытта субсидия суммасы хисап финанс елында авыл хуҗалыгы хайваннарының субсидияләнә торган нәселле ана баш санын асрау өчен субсидия алучының факттагы чыгымнар суммасыннан артмаска тиеш;

б) әлеге Тәртипнең 1 пунктындагы «б» пунктчасы нигезендә ($W_б$) (сумда) – түбәндәге формула буенча:

$$W_б = P_б \times S_б \times K_{соглб},$$

монда:

$P_б$ – агымдагы финанс елның 1 гыйнварына карата субсидия алучыда булган нәсел токымының сыйфаты буенча бәяләнгән яки әлеге сыйфатын бәяләү процессында булган нәселле үгезләрнең баш саны, баш;

$S_б$ – нәсел токымының сыйфаты буенча бәяләнгән яки әлеге сыйфатын бәяләү процессында булган нәселле үгезнең 1 башына 471 800,0 сум күләмендә субсидия ставкасы;

$K_{соглб}$ – ставкага карата кулланыла торган коэффициент:

хисап финанс елында субсидия алучы тарафыннан әлеге Тәртипнең 15 пунктындагы өченче абзацында каралган субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешелгәндә, ставкага карата хисап елы өчен факттагы күрсәткечкә тигез күләмдә, әмма иң күбе 1,2 булган коэффициент кулланыла;

хисап финанс елында субсидия алучы тарафыннан әлеге Тәртипнең 15 пунктындагы өченче абзацында каралган субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешелмәгәндә, ставкага карата хисап елы өчен факттагы күрсәткечкә тигез күләмдә, әмма кимендә 0,8 булган коэффициент кулланыла.

Шул ук вакытта субсидия суммасы субсидия алучының хисаплы финанс елында нәсел токымының сыйфаты буенча бәяләнгән яки әлеге сыйфатын бәяләү процессында булган нәселле үгезләрнең субсидияләнә торган баш санын асрау өчен факттагы чыгымнары суммасыннан артмаска тиеш;

в) әлеге Тәртипнең 1 пунктындагы «в» пунктчасы нигезендә ($W_в$) (сумда) – түбәндәге формула буенча:

$$W_в = C_в \times S_в \times K_{соглв},$$

монда:

$C_в$ – хисап һәм (яки) агымдагы финанс елларында субсидия алучы тарафыннан сөт һәм ит бирә торган мөгезле эре терлекнең нәселле яшь терлеген сатып алу кыйммәте, сум;

$S_м$ – сөт һәм ит бирә торган мөгезле эре терлекнең нәселле терлеген сатып алу кыйммәтенең 40 процентыннан исәпләнгән, әмма 1 башка күчереп исәпләгәндә 50,0 мең сумнан артмаган субсидия ставкасы, сум;

$K_{соглв}$ – ставкага карата кулланыла торган коэффициент:

хисап финанс елында субсидия алучы тарафыннан әлеге Тәртипнең

15 пунктындагы бишенче абзацында каралган субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешелгәндә, ставкага карата хисап елы өчен фактагы күрсәткечкә тигез күләмдә, әмма иң күбе 1,2 булган коэффициент кулланыла;

хисап финанс елында субсидия алучы тарафыннан әлеге Тәртипнең 15 пунктындагы бишенче абзацында каралган субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешелмәгәндә, ставкага карата хисап елы өчен фактагы күрсәткечкә тигез күләмдә, әмма кимендә 0,8 булган коэффициент кулланыла;

г) әлеге Тәртипнең 1 пунктындагы «г» пунктчасы нигезендә ($W_2$) (сумда) – түбәндәге формула буенча:

$$W_2 = P_6 \times K \times S_6 \times K_{соглг} + P_7 \times K \times S_7 \times K_{соглг} + P_8 \times K \times S_8 \times K_{соглг} + P_9 \times K \times \times S_9 \times K_{соглг},$$

монда:

$P_6$ – агымдагы финанс елының 1 гыйнварына карата беренче категориядәге субсидия алучыда булган, сөт бирә торган мөгезле эре терлекнең нәселле ана баш саны (сөт бирә торган нәсел хуҗалыгы категориясен билгеләү Министрлык тарафыннан әлеге Тәртипкә кушымта итеп бирелә торган методика нигезендә гамәлгә ашырыла), баш;

K – Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан хайваннарның тиешле төрләре буенча билгеләнә торган авыл хуҗалыгы терлекләренең нәселле баш санын шартлы башларга күчерү коэффициенты;

$S_6$ – беренче категориядәге субсидия алучылар өчен сөт бирә торган мөгезле эре терлекнең нәселле ана баш санының 1 шартлы башына 7 500,0 сум күләмендә субсидия ставкасы;

$K_{соглг}$ – ставкага карата кулланыла торган коэффициент:

хисап финанс елында субсидия алучы тарафыннан әлеге Тәртипнең 15 пунктындагы икенче абзацында каралган субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешелгәндә, ставкага карата хисап елы өчен фактагы күрсәткечкә тигез күләмдә, әмма иң күбе 1,2 булган коэффициент кулланыла;

хисап финанс елында субсидия алучы тарафыннан әлеге Тәртипнең 15 пунктындагы икенче абзацында каралган субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешелмәгәндә, ставкага карата хисап елы өчен фактагы күрсәткечкә тигез күләмдә, әмма кимендә 0,8 булган коэффициент кулланыла;

$P_7$ – агымдагы финанс елының 1 гыйнварына карата икенче категориядәге субсидия алучыда булган, сөт бирә торган мөгезле эре терлекнең нәселле ана баш саны, баш;

$S_7$ – икенче категориядәге субсидия алучылар өчен сөт бирә торган мөгезле эре терлекнең нәселле ана баш санының 1 шартлы башына 5 000,0 сум күләмендә субсидия ставкасы;

$P_8$ – агымдагы финанс елының 1 гыйнварына карата өченче категориядәге субсидия алучыда булган, сөт бирә торган мөгезле эре терлекнең нәселле ана баш саны, баш;

$S_8$ – өченче категориядәге субсидия алучылар өчен сөт бирә торган мөгезле эре терлекнең нәселле ана баш санының 1 шартлы башына 1 900,0 сум күләмендә субсидия ставкасы;

$P_9$ – агымдагы финанс елының 1 гыйнварына карата субсидия алучыда булган, ит бирә торган мөгезле эре терлекнең нәселле ана баш саны, баш;

$S_9$ – ит бирә торган мөгезле эре терлекнең нәселле ана баш санының 1 шартлы башына 5 000,0 сум күләмендә субсидия ставкасы.

Шул ук вакытта субсидия суммасы хисап финанс елында субсидия алучының мөгезле эре терлекнең нәселле ана баш санына карата селекция чаралары үткәрү чыгымнарының фактагы суммасыннан артмаска тиеш.»;

14 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Әлеге Тәртипнең 1 пунктындагы «г» пунктчасында күрсәтелгән юнәлеш буенча субсидия алучылар тарафыннан күрсәтелгән сайлап алу нәтиҗәләре буенча субсидия бирүгә ихтыяҗның гомуми күләме әлеге юнәлеш буенча бюджет йөкләмәләренең җиткерелгән лимитлары күләменнән артып киткән очракта, субсидия алучыга бирелергә тиешле субсидия суммасы ($W_{2к}$) Министрлык тарафыннан түбәндәге формула буенча билгеләнә

$$W_{2к} = W_2 \times K_{п1},$$

монда $K_{п1}$ – түбәндәге формула буенча билгеләнә торган төзәтү коэффициенты:

$$K_{п1} = \frac{V_г}{(\sum_{i=1}^{n} W_2)} \leq 1,$$

монда:

$V_г$ – әлеге Тәртипнең 1 пунктындагы «г» пунктчасында күрсәтелгән юнәлеш буенча каралган бюджет йөкләмәләренең җиткерелгән лимитлары күләме;

i – субсидия алучы;

n – әлеге Тәртипнең 1 пунктындагы «г» пунктчасы нигезендә субсидия алучылар саны.»;

15 пунктта:

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«әлеге Тәртипнең 1 пунктындагы «а» пунктчасы нигезендә – субсидия бирелгән елның 31 декабренә карата шартлы башларга (мең баш) исәпләгәндә авыл хуҗалыгы хайваннарының нәселле ана терлекләре саны субсидия бирелә торган елга кадәрге елның 31 декабренә карата авыл хуҗалыгы хайваннарының субсидияләнгән төрләренең кимендә фактагы нәселле ана терлекләре дәрәҗәсендә ирешелде;»;

түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«әлеге Тәртипнең 1 пунктындагы «г» пунктчасы нигезендә:

субсидия бирелгән елның 31 декабренә карата шартлы башларга (мең баш) исәпләгәндә мөгезле эре терлекнең нәселле ана терлекләре саны субсидия бирелә торган елга кадәрге елның 31 декабренә карата мөгезле эре терлекнең кимендә фактагы нәселле ана терлекләре дәрәҗәсендә ирешелде.»;

25 пунктта:

дүртенче абзацта «а» һәм «б» пунктчалары» сүзләрен «а», «б» һәм «г» пунктчалары» сүзләренә алмаштырырга;

уналтынчы абзацта «а» – «в» пунктчалары» сүзләрен «а», «б» һәм «г» пунктчалары» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«әлеге Тәртипнең 1 пунктындагы «г» пунктчасы нигезендә субсидия алу өчен – 1 баш өчен чыгымнарны күрсәтеп, селекция чараларын үткәрүгә факттагы чыгымнар турында белешмә кәгазе.»;

56 пунктта «исәп-хисап яки корреспондент» сүзләрен төшереп калдырырга;

61 пунктта татар текстында «Бирелгән субсидия» сүзләрен «Субсидия акчасы» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Агросәнәгать комплексында инвестиция кредитлары (заемнары) буенча процентлар түләү чыгымнарының бер өлешен каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджеттан финанслаша торган субсидия бирү тәртибендә:

5 пунктта:

«Бюджет» бүлегендә» сүзләрен «(бердәм портал бүлегендә)» сүзләренә алмаштырырга;

татар текстында «мәгълүмат» сүзеннән соң «субсидия бирү өчен бюджет ассигнованиеләре Министрлыкка җиткерелгән көннән соң килә торган көннән алып 10 эш көне эчендә» сүзләрен өстәргә;

55 пунктта «исәп-хисап яки корреспондент» сүзләрен төшереп калдырырга;

60 пунктта татар текстында «Бирелгән субсидия» сүзләрен «Субсидия акчасы» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Бәрәңге һәм яшелчәләр җитештерүне арттыруны стимуллау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджеттан финанслаша торган субсидия бирү тәртибендә:

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Әлеге Тәртип бәрәңге һәм яшелчә җитештерүне арттыруны стимуллау өчен түбәндәгеләргә Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджеттан финанслаша торган субсидия (алга таба – субсидия) бирү тәртибен һәм шартларын билгели:

а) агротехнологик эшләр башкару, авыл хуҗалыгы җитештерүенең экологик иминлеге дәрәҗәсен күтәрү, шулай ук туфракның уңдырышлылыгын арттыру һәм сыйфатын яхшырту чыгымнарының бер өлешен (өстәлгән кыйммәткә салымны исәпкә алмыйча) каплау өчен «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә кече эшкуарлык субъектларына кертү критерийларына җавап бирә торган, кече һәм урта эшкуарлык субъектларының бердәм реестрына кертелгән авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә (шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнардан һәм авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларыннан тыш) – субсидия алынган елда бәрәңге һәм ачык грунт яшелчә культуралары утыртырга планлаштырыла торган һәм (яки) билгән 1 гектар чәчүлек мәйданына ставка буенча;

б) авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә (шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнардан һәм авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларыннан тыш), фәнни һәм мәгариф оешмаларына:

элиталы орлыкчылыкка ярдәм күрсәтү чыгымнарының бер өлешен (өстәлгән кыйммәткә салымны исәпкә алмыйча) каплауга – субсидия алынган елда 1 тонна чәчелгән (утыртылган) бәрәңгенең һәм (яки) яшелчә культураларының элиталы һәм (яки) оригиналь орлыкларына (яшелчә культуралары гибридларын кертеп) ставка буенча;

өстәмә яктырту технологиясен кулланып җитештерелгән ябык грунт яшелчәләрен җитештерү чыгымнарының бер өлешен (өстәлгән кыйммәткә салымны исәпкә алмыйча) каплауга – субсидия алынган елда җитештерергә планлаштырыла торган һәм (яки) җитештерелгән 1 тонна үз җитештерүендәге ябык грунт яшелчә продукциясенә ставка буенча;

ачык грунт бәрәңге һәм яшелчәләр җитештерүгә ярдәм күрсәтү чыгымнарының бер өлешен (өстәлгән кыйммәткә салымны исәпкә алмыйча) каплауга – субсидия алынган елда җитештерергә планлаштырыла торган һәм (яки) җитештерелгән 1 тонна бәрәңге һәм ачык грунт яшелчәсенә ставка буенча.»;

2 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«фәнни һәм мәгариф оешмалары – фәнни, фәнни-техник һәм (яки) мәгариф эшчәнлеге барышында «Авыл хуҗалыгын үстерү турында» 2006 елның 29 декабрендәге 264-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясындагы 1 өлешендә күрсәтелгән исемлек нигезендә авыл хуҗалыгы продукциясе җитештерүне, аны беренчел һәм аннан соңгы (сәнәгый) эшкәртүне гамәлгә ашыра торган фәнни оешмалар, һөнәри белем бирү оешмалары, югары белем бирү мәгариф оешмалары;

б) сайлап алуда катнашучылар – авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре (шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнардан һәм авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларыннан тыш), фәнни һәм мәгариф оешмалары.»;

5 пунктта:

«Бюджет» бүлегендә» сүзләрен «(бердәм портал бүлегендә)» сүзләренә алмаштырырга;

татар текстында «мәгълүмат» сүзеннән соң «субсидия бирү өчен бюджет ассигнованиеләре Министрлыкка җиткерелгән көннән соң килә торган көннән алып 10 эш көне эчендә» сүзләрен өстәргә;

11 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11. Субсидия түбәндәгеләр буенча бирелә:

а) әлеге Тәртипнең 1 пунктындагы «а» пунктчасында күрсәтелгән юнәлеш буенча – акча алучылар тарафыннан агротехнологик эшләр башкарганда чәчү өчен авыл хуҗалыгы үсемлекләре орлыклары кулланылу шарты белән:

сорт һәм чәчү (утырту) сыйфатлары күрсәткечләре «Орлыкчылык турында» 2021 елның 30 декабрендәге 454-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясындагы 3 өлеше нигезендә сорт һәм чәчү (утырту) сыйфатлары күрсәткечләрен билгеләү датасына карата әлеге Федераль законның 13 статьясындагы 2 өлеше нигезендә Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан билгеләнгән авыл хуҗалыгы үсемлекләре орлыкларының сорт һәм чәчү (утырту) сыйфаты күрсәткечләренә карата таләпләргә туры килә торган (әгәр авыл хуҗалыгы үсемлекләренең ыруглары һәм төрләре Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2022 елның 8 декабрендәге б-3835 номерлы боерыгы белән расланган Файдаланырга рөхсәт ителгән авыл хуҗалыгы үсемлекләре сортлары һәм гибридларының дәүләт реестрына сортлары

һәм гибридлары кертелергә тиешле, җитештерелүе һәм үстерелүе Россия Федерациясенең азык-төлек иминлеген тәэмин итүгә юнәлдерелгән авыл хуҗалыгы үсемлекләре ыруглары һәм төрләре исемлегендә (алга таба – авыл хуҗалыгы үсемлекләре төрләре исемлеге) булса);

сорт һәм чәчү (утырту) сыйфатлары күрсәткечләре «Яшелчә, бакча культуралары, тамыразыклар һәм азык кәбестәсе орлыклары. Сорт һәм чәчү сыйфатлары. Гомуми техник шартлар» ГОСТ 32592-2013 дәүләтара стандартына (2013 елның 27 декабрендә кабул ителде һәм 2015 елның 1 июлендә гамәлгә кертелде), «Сарымсак орлыгы. Сорт һәм чәчү сыйфатлары. Гомуми техник шартлар» ГОСТ 30106-94 халыкара стандартына (1994 елның 21 октябрендә кабул ителде һәм 1996 елның 1 гыйнварыннан гамәлгә кертелде), «Драже кебек эшкәртелгән яшелчә культуралары һәм азык чөгендере орлыклары. Чәчү сыйфатлары. Гомуми техник шартлар» ГОСТ 32917-2014 дәүләтара стандартына (2014 елның 14 ноябрендә кабул ителде һәм 2016 елның 1 гыйнварыннан гамәлгә кертелде), «Утырта торган вак башлы суган һәм утырта торган зур башлы суган. Чәчү сыйфатлары. Гомуми техник шартлар» ГОСТ 30088-93 дәүләтара стандартына (1994 елның 15 апрелендә кабул ителде һәм 1995 елның 1 гыйнварыннан гамәлгә кертелде) туры килә (әгәр авыл хуҗалыгы үсемлекләренең ыруглары һәм төрләре авыл хуҗалыгы үсемлекләре төрләре исемлегенә кермәгән очракта);

б) әлеге Тәртипнең 1 пунктындагы «б» пунктчасының өченче абзацында күрсәтелгән юнәлеш буенча – акча алучы тарафыннан Министрлыкка өстәмә яктырту технологиясен кулланып җитештерелгән үз җитештерүендәге ябык грунт яшелчәләре уңышлары җыелган барлык мәйданда Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан өстәмә яктырту куәтенә һәм 1 гектар җитештерү мәйданы яшелчәләре уңышына карата билгеләнгән таләпләргә туры килә торган электрлы өстәмә яктырту җайланмасы һәм аны куллануны раслый торган документлар бирелү шарты белән;

в) әлеге Тәртипнең 1 пунктындагы «б» пунктчасының дүртенче абзацында күрсәтелгән юнәлеш буенча – түбәндәге шартларны исәпкә алып:

бәрәңге һәм ачык грунт яшелчәләрен җитештергәндә кулланыла торган ашламаларны алга таба кертү өчен чәчүлекләрнең (утырту урыннарының) 1 гектарына гамәлдәге матдәгә күчереп исәпләгәндә кимендә 20 килограмм күләмендә сатып алу;

Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы ведомствосы буйсынуында булган, акча алучы эшчәнлек гамәлгә ашырган мелиорация өлкәсендәге федераль дәүләт бюджет учреждениесенең (алга таба – учреждение) учреждениегә акча алучының су бирү һәм (яки) чыгару хезмәтләре өчен үз вакытында түләнмәгән бурычы һәм (яки) әлеге учреждениенең суд тарафыннан эшкә алынган субсидия алучыдан су бирү һәм (яки) чыгару хезмәтләре күрсәтү шартнамәсе буенча 50 мең сумнан арткан күләмдә бурыч акчасын түләтү турында дәгъва гаризасы булмау хакында белешмә кәгазе булу (әлеге белешмә кәгазе булмаса, Министрлык аны мөстәкыйль рәвештә, шул исәптән берничә акча алучыга карата соратып ала);

авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрнең дәүләт реестрында ярдәм итү максаты белән Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрнең дәүләт реестрын алып бару тәртибе турында» 2023 елның

2 февралендәге 154 номерлы карары белән расланган Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрнең дәүләт реестрын алып бару кагыйдәләренең 1 нче кушымтасындагы 1, 2, 5, 14, 17, 18 һәм 20 пунктларында каралган акча юнәлдерелгән, үсемлекчелек продукциясе авыл хуҗалыгында җитештерелә торган яки җитештерергә планлаштырыла торган җир кишәрлеге турында белешмәләр булу;

авыл хуҗалыгы үсемлекләренең орлыкларын һәм утырту материалын куллану:

сорт һәм чәчү (утырту) сыйфатлары күрсәткечләре «Орлыкчылык турында» 2021 елның 30 декабрендәге 454-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясындагы 3 өлеше нигезендә сорт һәм чәчү (утырту) сыйфатлары күрсәткечләрен билгеләү датасына Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан билгеләнгән авыл хуҗалыгы үсемлекләре орлыкларының сорт һәм чәчү (утырту) сыйфаты күрсәткечләренә карата таләпләргә туры килә торган (әгәр авыл хуҗалыгы үсемлекләренең ыруглары һәм төрләре авыл хуҗалыгы үсемлекләре төрләре исемлегендә булса);

сорт һәм чәчү (утырту) сыйфатлары күрсәткечләре «Яшелчә, бакча культуралары, тамыразыклар һәм азык кәбестәсе орлыклары. Сорт һәм чәчү сыйфатлары. Гомуми техник шартлар» ГОСТ 32592-2013 дәүләтара стандартына (2013 елның 27 декабрендә кабул ителде һәм 2015 елның 1 июлендә гамәлгә кертелде), «Сарымсак орлыгы. Сорт һәм чәчү сыйфатлары. Гомуми техник шартлар» ГОСТ 30106-94 халыкара стандартына (1994 елның 21 октябрендә кабул ителде һәм 1996 елның 1 гыйнварыннан гамәлгә кертелде), «Драже кебек эшкәртелгән яшелчә культуралары һәм азык чөгендере орлыклары. Чәчү сыйфатлары. Гомуми техник шартлар» ГОСТ 32917-2014 дәүләтара стандартына (2014 елның 14 ноябрендә кабул ителде һәм 2016 елның 1 гыйнварыннан гамәлгә кертелде), «Утырта торган вак башлы суган һәм утырта торган зур башлы суган. Чәчү сыйфатлары. Гомуми техник шартлар» ГОСТ 30088-93 дәүләтара стандартына (1994 елның 15 апрелендә кабул ителде һәм 1995 елның 1 гыйнварыннан гамәлгә кертелде) туры килә (әгәр авыл хуҗалыгы үсемлекләренең ыруглары һәм төрләре авыл хуҗалыгы үсемлекләре төрләре исемлегенә кермәгән очракта).»;

14 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«14. Субсидия алучыларга бирелә торган субсидия күләме:

әлеге Тәртипнең 1 пунктындагы «а» пунктчасы нигезендә (W) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$W = (P \times S) + (P_{отеч} \times S \times 2),$$

монда:

P – агымдагы финанс елында бәрәңге һәм (яки) ачык грунт яшелчә культуралары утыртырга планлаштырыла торган һәм (яки) билгән мәйдан (үз илебез селекциясендәге бәрәңге һәм (яки) ачык грунт яшелчә культуралары утыртырга планлаштырыла торган һәм (яки) билгән мәйданнан тыш), гектар;

S – Министрлык боерыгы белән раслана торган бәрәңге һәм (яки) ачык грунт яшелчә культуралары утыртырга планлаштырыла торган һәм (яки) билгән 1 гектар чәчү мәйданына субсидия ставкасы, сум;

$P_{отеч}$ – үз илебез селекциясендәге бәрәңге һәм (яки) ачык грунт яшелчә культуралары утыртырга планлаштырыла торган һәм (яки) биләгән мәйдан, гектар;

2 – үз илебез селекциясендәге бәрәңге һәм ачык грунт яшелчә культуралары утыртырга планлаштырыла торган һәм (яки) утыртылган 1 гектар чәчү мәйданына субсидия ставкасына карата арттыру коэффициенты;

әлеге Тәртипнең 1 пунктындагы «б» пунктчасының икенче абзацы нигезендә ($W_{эос}$) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$W_{эос}= (V_{эос} \times S_{эос}) + (V_{эос\ отеч} \times S_{эос} \times 2),$$

монда:

$V_{эос}$ – субсидия алучы тарафыннан сатып алынган, субсидия алынган елда чәчелгән (утыртылган) бәрәңгенең һәм (яки) яшелчә культураларының элиталы һәм (яки) оригиналь орлыклары (бәрәңге һәм (яки) яшелчә культуралары орлыкларыннан (үз илебез селекциясендәге яшелчә культуралары гибридларын кертеп) тыш), тонна;

$S_{эос}$ – субсидия алынган елда сатып алынган һәм чәчелгән (утыртылган) бәрәңгенең һәм яшелчә культураларының 1 тонна элиталы һәм (яки) оригиналь орлыклары өчен Министрлык боерыгы белән раслан торган субсидия ставкасы, сум;

$V_{эос\ отеч}$ – субсидия алынган елда чәчелгән (утыртылган) бәрәңгенең һәм (яки) яшелчә культураларының элиталы һәм (яки) оригиналь орлыклары (үз илебез селекциясендәге яшелчә культуралары гибридларын кертеп) күләме, тонна;

2 – субсидия алынган елда сатып алынган һәм чәчелгән (утыртылган) бәрәңгенең һәм яшелчә культураларының 1 тонна элиталы һәм (яки) оригиналь орлыклары (үз илебез селекциясендәге яшелчә культуралары гибридларын кертеп) өчен субсидия ставкасына карата арттыру коэффициенты.

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2017 – 2030 елларга Авыл хуҗалыгын үстерү буенча федераль фәнни-техник программаны раслау турында» 2017 елның 25 августындагы 996 номерлы карары белән расланган Авыл хуҗалыгын үстерү буенча федераль фәнни-техник программа кысаларында җитештерелгән бәрәңге һәм (яки) яшелчә культуралары орлыкларын сатып алу чыгымнарының бер өлешен каплаган очракта, Россия Федерациясе субъекты тарафыннан билгеләнгән ставка күләме чыгымнарның 70 процентыннан (Министрлык тарафыннан мондый орлыклар сатуның иң чик кыйммәтеннән артмый торган кыйммәттән чыгып) арта алмый;

әлеге Тәртипнең 1 пунктындагы «б» пунктчасының өченче абзацы нигезендә ($W_{озг}$) (сумда) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$W_{озг}= (V_{озг1} \times S_{озг}) + (V_{озг2} \times 3),$$

монда:

$V_{озг1}$ – сайлап алуда катнашучының 1 майдан алып 31 декабрьгә кадәр агымдагы финанс елында җитештерелгән ябык типтагы яшелчә күләмнәре турындагы белешмә кәгазе нигезендә агымдагы финанс елында җитештерергә планлаштырыла торган һәм (яки) җитештерелгән үз җитештерүендәге ябык грунт яшелчә продукциясе күләме, тонна;

$S_{озг}$ – 1 тонна ябык грунт яшелчә культуралары өчен Министрлык боерыгы белән раслана торган субсидия ставкасы, сум;

$V_{озг2}$ – сайлап алуда катнашучының 1 гыйнвардан алып 30 апрельгә кадәр агымдагы финанс елында җитештерелгән ябык типтагы яшелчә күләмнәре турындагы белешмә кәгазе нигезендә агымдагы финанс елында җитештерергә планлаштырыла торган һәм (яки) җитештерелгән үз җитештерүендәге ябык грунт яшелчә продукциясе күләме, тонна;

3 – 1 гыйнвардан алып 30 апрельгә кадәр агымдагы финанс елында җитештерергә планлаштырыла торган һәм (яки) җитештерелгән үз җитештерүендәге ябык грунт яшелчә продукциясе күләме өчен субсидия ставкасына карата арттыру коэффициенты;

әлеге Тәртипнең 1 пунктындагы «б» пунктчасының дүртенче абзацы нигезендә ($W_п$) (сумда) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$W_п = (V_п \times S_п) + (V_{п\ отеч} \times S_п \times 2),$$

монда:

$V_п$ – сайлап алуда катнашучының агымдагы финанс елында бәрәңге һәм (яки) ачык грунт яшелчәләре җитештерү күләмнәре турындагы белешмә кәгазе нигезендә агымдагы финанс елында җитештерергә планлаштырыла торган һәм (яки) җитештерелгән бәрәңге һәм (яки) ачык грунт яшелчәләре күләме (җитештерергә планлаштырыла торган һәм (яки) җитештерелгән үз илебез селекциясендәге бәрәңге һәм (яки) ачык грунт яшелчәләре күләменнән тыш), тонна;

$S_п$ – җитештерергә планлаштырыла торган һәм (яки) җитештерелгән 1 тонна бәрәңге һәм ачык грунт яшелчәләре өчен Министрлык боерыгы белән раслана торган субсидия ставкасы, сум;

$V_{п\ отеч}$ – җитештерергә планлаштырыла торган һәм (яки) җитештерелгән үз илебез селекциясендәге бәрәңге һәм (яки) ачык грунт яшелчәләре күләме, тонна;

2 – җитештерергә планлаштырыла торган һәм (яки) җитештерелгән үз илебез селекциясендәге бәрәңге һәм (яки) ачык грунт яшелчәләре күләме өчен субсидия ставкасына карата арттыру коэффициенты.»;

15 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«15. Субсидия бирү нәтиҗәләре:

әлеге Тәртипнең 1 пунктындагы «а» пунктчасында күрсәтелгән юнәлеш буенча:

субсидия бирелгән елның 1 июленә карата авыл хуҗалыгы оешмаларында, крестьян (фермер) хуҗалыкларында (индивидуаль эшкуарларны да кертеп) бәрәңге утыртылды, гектар;

субсидия бирелгән елның 1 июленә карата авыл хуҗалыгы оешмаларында, крестьян (фермер) хуҗалыкларында (индивидуаль эшкуарларны да кертеп) ачык грунт яшелчәләре утыртылды, гектар;

әлеге Тәртипнең 1 пунктындагы «б» пунктчасының икенче абзацында күрсәтелгән юнәлеш буенча – субсидия бирелгән елның 31 декабренә карата элиталы һәм (яки) оригиналь бәрәңге орлыгын һәм яшелчә культуралары орлыгын чәчү күләменә ирешелде;

әлеге Тәртипнең 1 пунктындагы «б» пунктчасының өченче абзацында күрсәтелгән юнәлеш буенча – субсидия бирелгән елның 31 декабренә карата өстәмә яктырту технологиясен кулланып үстерелгән үз җитештерүендәге ябык грунт яшелчә продукциясе җитештерелде, тонна;

әлеге Тәртипнең 1 пунктындагы «б» пунктчасының дүртенче абзацында күрсәтелгән юнәлеш буенча:

субсидия бирелгән елның 31 декабренә карата авыл хуҗалыгы оешмаларында, крестьян (фермер) хуҗалыкларында һәм индивидуаль эшкуарларда бәрәңге җитештерелде, тонна;

субсидия бирелгән елның 31 декабренә карата авыл хуҗалыгы оешмаларында, крестьян (фермер) хуҗалыкларында һәм индивидуаль эшкуарларда ачык грунт яшелчәләре җитештерелде, тонна.»;

25 пунктта:

бишенче абзацта «һәм «б» сүзләрен төшереп калдырырга, «1 пунктның икенче абзацында» сүзләрен «1 пунктның «а» пунктчасында» сүзләренә алмаштырырга;

алтынчы абзацта «1 пунктның «в», «д» һәм «е» пунктчасында» сүзләрен

«1 пунктның «б» пунктчасындагы икенче һәм дүртенче абзацларында» сүзләренә алмаштырырга;

җиденче абзацта «1 пунктның «в» пунктчасында» сүзләрен «1 пунктның «б» пунктчасындагы икенче абзацында» сүзләренә алмаштырырга;

сигезенче абзацта «1 пунктның «г» пунктчасы белән» сүзләрен «1 пунктның «б» пунктчасындагы өченче абзацы белән» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Әлеге Тәртипнең 1 пунктындагы «б» пунктчасының дүртенче абзацы нигезендә субсидия алу өчен сайлап алуда катнашучылар түбәндәгеләрне өстәмә бирә:

Министрлык тарафыннан расланган форма буенча агымдагы финанс елында җитештерергә планлаштырыла торган бәрәңге һәм (яки) ачык грунт яшелчәләре күләмнәре турында белешмә кәгазенең электрон күчермәсе;

Министрлык боерыгы белән расланган форма буенча агымдагы финанс елында бәрәңге һәм ачык грунт яшелчәләрен җитештерү гамәлгә ашырыла яки гамәлгә ашырырга планлаштырыла торган авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрнең дәүләт реестрына кертелгән җир кишәрлекләре паспортлары реестры.»;

55 пунктның икенче абзацында «исәп-хисап яки корреспондент» сүзләрен төшереп калдырырга;

60 пунктта татар текстында «Бирелгән субсидия» сүзләрен «Субсидия акчасы» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Саклагычлар төзүгә һәм (яисә) модернизацияләүгә турыдан-туры тотылган чыгымнарның бер өлешен каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджеттан финанслаша торган субсидия бирү тәртибендә:

2 пунктның сигезенче абзацында «яки» сүзен «һәм» сүзенә алмаштырырга;

5 пунктта:

«Бюджет» бүлегендә» сүзләрен «(бердәм портал бүлегендә)» сүзләренә алмаштырырга;

татар текстында «мәгълүмат» сүзеннән соң «субсидия бирү өчен бюджет ассигнованиеләре Министрлыкка җиткерелгән көннән соң килә торган көннән алып 10 эш көне эчендә» сүзләрен өстәргә;

11 пунктның икенче абзацында «кагыла» сүзен «гамәлдә була» сүзләренә алмаштырырга;

55 пунктта «исәп-хисап яки корреспондент» сүзләрен төшереп калдырырга;

59 пунктта татар текстында «Бирелгән субсидия» сүзләрен «Субсидия акчасы» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Агросәнәгать комплексы объектларын төзүгә һәм (яисә) модернизацияләүгә турыдан-туры тотылган чыгымнарның бер өлешен каплау, шулай ук федераль бюджеттан финанслаша торган сөт продукциясенең аерым төрләрен мәҗбүри маркировкалауны гамәлгә кертү өчен маркировка җиһазлары сатып алу һәм аларны сәнәгатьтә файдалануга кертү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибендә:

5 пунктта:

«Бюджет» бүлегендә» сүзләрен «(бердәм портал бүлегендә)» сүзләренә алмаштырырга;

татар текстында «мәгълүмат» сүзеннән соң «субсидия бирү өчен бюджет ассигнованиеләре Министрлыкка җиткерелгән көннән соң килә торган көннән алып 10 эш көне эчендә» сүзләрен өстәргә;

55 пунктта «исәп-хисап яки корреспондент» сүзләрен төшереп калдырырга;

60 пунктта татар текстында «Бирелгән субсидия» сүзләрен «Субсидия акчасы» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Озын сүсле җитен һәм (яисә) техник киндер җитештерүгә ярдәм күрсәтү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджеттан финанслаша торган субсидия бирү тәртибендә:

4 пунктта:

«Бюджет» бүлегендә» сүзләрен «(бердәм портал бүлегендә)» сүзләренә алмаштырырга;

татар текстында «мәгълүмат» сүзеннән соң «субсидия бирү өчен бюджет ассигнованиеләре Министрлыкка җиткерелгән көннән соң килә торган көннән алып 10 эш көне эчендә» сүзләрен өстәргә;

11 пунктта:

«а» пунктчасының икенче һәм өченче абзацларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«сорт һәм чәчү (утырту) сыйфатлары күрсәткечләре «Орлыкчылык турында» 2021 елның 30 декабрендәге 454-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясындагы 3 өлеше нигезендә сорт һәм чәчү (утырту) сыйфатлары күрсәткечләрен билгеләү датасына Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан билгеләнгән авыл хуҗалыгы үсемлекләре орлыкларының сорт һәм чәчү (утырту) сыйфаты күрсәткечләренә карата таләпләргә туры килә торган (әгәр авыл хуҗалыгы үсемлекләренең ыруглары һәм төрләре авыл хуҗалыгы үсемлекләре төрләре исемлегендә булса);

сорт һәм чәчү (утырту) сыйфатлары күрсәткечләре «Авыл хуҗалыгы үсемлекләре орлыклары. Сорт һәм чәчү сыйфатлары. Гомуми техник шартлар» ГОСТ Р 52325-2005 Россия Федерациясе илкүләм стандартына (2005 елның 23 мартында

расланды һәм 2006 елның 1 гыйнварыннан гамәлгә кертелде) туры килә торган (әгәр авыл хуҗалыгы үсемлекләренең ыруглары һәм төрләре авыл хуҗалыгы үсемлекләре төрләре исемлегенә кермәсә);»;

«д» пунктчасында татар текстында «административ җаваплылыкка» сүзләре алдына «субсидия алучыларны (вазыйфаи һәм юридик затларны)» сүзләрен өстәргә;

«ж» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«ж) субсидия алучылар тарафыннан Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрнең дәүләт реестрын алып бару тәртибе турында» 2023 елның 2 февралендәге 154 номерлы карары белән расланган Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрнең дәүләт реестрын алып бару кагыйдәләренә 1 нче кушымтаның 1, 2, 5, 14, 17, 18 һәм 20 пунктлары нигезендә белешмәләр тапшырылу.»;

13 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«13. Субсидия алучыга бирелә торган субсидия күләме (W) (сумда) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$W = (V \times 0,25 \times C) \times K_{согл},$$

монда:

V – агымдагы финанс елына кадәрге елда һәм (яки) агымдагы финанс елында Россия Федерациясе территориясендә урнашкан эшкәртү оешмаларына сатылган үз җитештерүендәге эшкәртелгән җитен саламы һәм (яисә) эшкәртелгән киндер саламы һәм (яисә) үз җитештерүгә төяп җибәрелгән әлеге саламнар күләме, тонна;

0,25 – эшкәртелгән җитен саламыннан һәм (яисә) эшкәртелгән киндер саламыннан җепселнең уртача чыгышы;

C – Министрлык боерыгы белән раслана торган 1 тонна эшкәртелгән җитен саламы һәм (яисә) эшкәртелгән киндер саламы өчен субсидия ставкасы;

$K_{согл}$ – ставкага карата кулланыла торган коэффициент:

субсидия алучы тарафыннан агымдагы финанс елына кадәрге елда әлеге Тәртипнең 14 пунктында каралган субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешелгән очракта, ставкага карата хисап елы өчен билгеләнгән, факттагы күрсәткечкә тигез булган, әмма 1,2дән артмаган күләмдә коэффициент кулланыла;

субсидия алучы тарафыннан агымдагы финанс елына кадәрге елда әлеге Тәртипнең 14 пунктында каралган субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешелмәгән очракта, ставкага карата хисап елы өчен билгеләнгән, факттагы күрсәткечкә тигез булган, әмма кимендә 0,8 күләмдә коэффициент кулланыла;

Субсидия алучыга бирелә торган субсидия күләме агымдагы финанс елына кадәрге елда җитештерелгән җитен-бурычлы кеше һәм (яисә) техник киндер җитештерүгә бәйле факттагы чыгымнар күләменнән артып китә алмый.»;

29 пунктның «а» пунктчасындагы унөченче абзацы үз көчен югалткан дип танырга;

54 пунктның икенче абзацында «исәп-хисап яки корреспондент» сүзләрен төшереп калдырырга;

59 пунктта татар текстында «Бирелгән субсидия» сүзләрен «Субсидия акчасы» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Молекуляр генетик экспертиза үткәрү чыгымнарының бер өлешен каплау өчен нәсел хуҗалыкларына Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджеттан финанслаша торган субсидия бирү тәртибендә:

5 пунктта:

«Бюджет» бүлегендә» сүзләрен «(бердәм портал бүлегендә)» сүзләренә алмаштырырга;

татар текстында «мәгълүмат» сүзеннән соң «субсидия бирү өчен бюджет ассигнованиеләре Министрлыкка җиткерелгән көннән соң килә торган көннән алып 10 эш көне эчендә» сүзләрен өстәргә;

54 пунктта «исәп-хисап яки корреспондент» сүзләрен төшереп калдырырга;

58 пунктта татар текстында «Бирелгән субсидия» сүзләрен «Субсидия акчасы» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карарга Мөгезле эре терлек, кәҗә һәм сарык сөтен азык-төлек продукциясенә эшкәртү өчен ярдәм күрсәтүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджеттан финанслаша торган субсидия бирү тәртибен (карарга теркәлә) өстәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин